**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.05.2018 № 360

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урам исемнәре күрсәткечләрен Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дөрес язу тәртибен раслау турында

"Россия Федерациясендә муниципаль үзидарәнең гомум принциплары турында» 2006 елның 10 октябрендәге 131 нче ФЗ, "Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII нче Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасында татар телен дәүләт теле буларак куллану турында" 2013 елның 12 январендәге 1-ЗРТ Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә төрле төрдәге урам исемнәре күрсәткечләрен дөрес язу тәртибен булдыру максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урам исемнәре күрсәткечләрен Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дөрес язу тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2.Төзекләндерү эшләрендә катнашучы физик һәм оештыру-хокукый формадан бәйсез рәвештә юридик затларга урам исемнәре күрсәткечләрен рәсмиләштергәндә һәм урнаштырганда дөрес язылышны билгеләүче әлеге Тәртипкә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

3.Әлеге карарны Нурлат муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4.Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.С. Әхмәтшин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2018 ел, 24 май, 360 номерлы
карары белән расланган 1 нче кушымта

**Татарстан республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урам исемнәре күрсәткечләрен дөрес язу тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Әлеге регламент 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында" Федераль Закон, Татарстан Республикасының 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы "Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" законы, Татарстан Республикасының 2013 елның 12 январендагы 1-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында татар телен дәүләт теле буларак турында" законы нигезендә эшләнеп, Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урам, проспект, тыкырык, мәйдан исемнәре, барлык күчемсез милек объектлары исемнәре күрсәткечләрен рәсмиләштерү һәм урнаштыру тәртибен билгели.

1.2.Әлеге регламент Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының бөтен территориясендә гамәлгә ашырылырга һәм барлык юридик һәм физик затлар тарафыннан үтәлергә хокуклы.

1.3.Әлеге кагыйдәләрне кулланылышка кертүнең максаты булып Нурлат муниципаль рйоны территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урам исемнәре күрсәткечләрен рәсмиләштерү таләпләрен системалаштыру тора.

## 2. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урам исемнәре күрсәткечләрен рәсмиләштерү һәм урнаштыруга төп таләпләр

2.1.Урам, проспект, тыкырык, мәйдан исемнәре, барлык күчемсез милек объектлары исемнәре күрсәткечләре Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә (рус һәм татар телләрендә) языла һәм урнаштырыла (1 нче кушымта).

2.2.Биналарның алгы якларына:
үзирекле рәвештә урам, проспект, тыкырык, мәйдан исемнәре күрсәткечләрен урнаштыру;

тиешле таләпләргә туры килмәүче урам исемнәре күрсәткечләре урнаштыру;

урам исемнәре күрсәткечләре янәшәсенә артык чыгып торучы язмалы такталар, ярдәмче терәкләр, шулай ук аларның кабул ителешенә комачаулый торган объектлар урнаштыру;

урам исемнәре язуларын биналарның чыгып тора торган өлешләре янәшәсенә яки фасадның эчкә кереп тора торган өлешенә, бизәк, кәрниз, капкаларга урнаштыру;

үзирекле рәвештә урам исемнәре күрсәткечләрен урыныннан күчерү тыела.

2.3.Биналарга урам исемнәре язылган күрсәткечләр урнаштырылырга һәм алар төзек һәм чиста хәлдә тотылырга тиеш.

2.4.Татар һәм рус телләрендә урам исемнәре күрсәткечләрен рәсмиләштергәндә язма хәрефләр бер үк зурлыкта булырга тиеш.

2.5.Татар телендә яки рус телендә текстның күләме зуррак булуына карап, хәреф шрифтын аз гына кечерәйтергә мөмкин.

2.6. Рус һәм татар телләрендәге текстларның төсләре бертөрле булырга тиеш.

2.7.Алтакталар, мәгълүмат бирүче таблицалар, билгеләнгән стандартларга бәйле рәвештә, яхшы укып булырлык биеклектә эленергә тиеш.

**3.Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урам исемнәре күрсәткечләрен язу һәм урнаштыру тәртибе**

2.1. Урам, проспект, тыкырык, мәйдан исеме күрсәткечләре барлык күчемсез милек объектларында түбәндәге таләпләргә туры китерелеп урнаштырыла:

урам, проспект, тыкырык, мәйдан исеме күрсәткечләре җәяү һәм транспорт белән хәрәкәт иткәндә, яхшы күренә торган җиргә, ераклык, биеклек, биналарның төзелеш үзенчәлеге, биек агачлар исәпкә алынып урнаштырыла;

урам, проспект, саннар белән язылган тыкырык, мәйдан атамалары күрсәткечләре юл чатындагы бина диварының ике ягына да урнаштырыла;

язулы күрсәткеч бинага тигез, туры итеп һәм янәшә биналардагы күрсәткечләр белән бертигез итеп эленергә, бинаның алгы ягында архитектура детальләре комачауламаган, башка объектлар (агач, корылмалар) капламаган ачык җиргә урнаштырыла;

проспект, урам, саннар белән язылган тыкырык, мәйдан исемнәре язылган күрсәткечләрне 2,5нан алып 3,5м га кадәр биеклектә (заманча төзелгән биналарда 5,0 м) бина почмагыннан 1,0 м дан да артык булмаган ераклыкта кую мөһим;

урам чатларында урам исемнәре күрсәткечләре шушы чатка карауучы бинага урнаштырыла;

проспект, урам, саннар белән язылган тыкырык, мәйдан исемнәре язылган күрсәткечләр бинаның алгы ягында уң якта, аралыкта, транспорт өчен бер яклы хәрәкәт булган урамнарда биналарның хәрәкәт уңаена якын фасад өлешендә, арка янында яки кергән җирдә ишектән уң якта; ишегалдына караган биналарда – керү юлы ягындагы диварның буш аралыгында, сәнәгать оешмаларының корылмаларында һәм коймаларында –төп керү урыныннан уң якта урнаштырыла.

3.2.Урам исемнәре язылышы Нурлат муниципаль районы урамнар Реестры таләпләре буенча рус һәм татар телләрендә башкарыла. Күрсәткечләрдәге исемнәр рус һәм татар телләрендә төгәл һәм тулысынча язылырга тиеш. Проспект, урам, тыкырык сүзләре рус һәм татар телләрендә тулы вариантта языла.

Урам исеме баш хәрефтән языла, ә проспект, урам, тыкырык сүзләре – юл хәрефеннән.

3.3.Яраксыз хәлгә килгән урам исемнәре күрсәткечләре вакытында төзекләндерелергә яки алыштырылырга тиеш.

3.4.Вәкаләтле оешма раславыннан башка урам, проспект, тыкырык, мәйдан исемнәрен, бина, корылмалар номерын урнаштыру һәм куллану тыела.

## 3. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урам исемнәре күрсәткечләрен урнаштыру һәм рәсмиләштерү өлкәсендә җаваплылык

4.1. Яраксыз һәм таушалган хәлдә яки урам исемнәре күрсәткечләре бөтенләй булмаганда, тиешле таләпләргә туры килми торган урам күрсәткечләре урнаштырылган очракта, күчемсез милек хуҗалары яки бинаны кулланучы юридик һәм физик затларга законнар нигезендә җаваплылык йөкләнә.